ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.07.2023 с.Старое Дрожжаное №308

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын эшләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 31 декабрендәге 507-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының 2023 елның 20 июлендәге авыл җирлекләренең Җирдән файдалану һәм төзелеше кагыйдәләре проектларын эшләү буенча даими эшләүче Комиссия бәяләмәсен исәпкә алып һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә (алга таба – Проект).
2. Проектның заказчысы итеп Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетын билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Авыл җирлекләренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектларын әзерләү буенча даими эшләүче Комиссиягә әзерләнгән проектны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31, 32, 33 статьялары таләпләре нигезендә карап тикшерергә, килештерергә һәм җибәрергә.
4. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең

инфраструктур үсеш буенча урынбасары Р.Р. Багаутдиновка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Р.И. Мөхәмәтҗанов